| | **прилагательных и их образование, правописание и употребление в речи.** | | | | |
| 56 | Сыйфатларның җөмләдә иярчен кисәк һәм хәбәр булып килүе.<br>**Роль имен прилагательных в предложении.** | 1 | | | |
| 57 | Сыйфатларның туры һәм күчерелмә мәгънәдә кулланылуы.<br>**Употребление прилагательных в прямом и переносном значении.** | 1 | | | |
| 58 | Синоним һәм антоним сыйфатларын сөйләмдә куллану.**Употребление в речи имен прилагательных – синонимов и имен прилагательных - антонимов.** | 1 | | | |
| 59 | **Контроль эш. Грамматик биремле диктант.** | 1 | | | |
| 60 | Сыйфат бүлеген кабатлау. Үз-үзеңне тикшер!**Повторение раздела — Имя прилагательное** | 1 | | | |
| Алмашлык(7сәг.) | | | | | |
| 61 | Алмашлык – мөстәкыйль сүз төркеме, башка сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, сан, рәвешне) алмаштырып килүе.Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше һәм дөрес язылышы.<br>**Местоимение как часть речи. Личные местоимения, их значение , употребление в речи. Личные местоимения 1. 2. 3 лица. Число личных местоимений. Изменение личных местоимений попадежам и их правописание** | 1 | | | |
| 62 | Зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүе.**Послелоги с личными местоимениями.** | 1 | | | |
| 63 | Сорау алмашлыклары. Килеш сораулары – сорау алмашлыклары.<br>**Вопросительные местоимения. Падежные вопросы - вопросительные местоимения.** | 1 | | | |
| 64 | Алмашлыкларның сөйләмдә роле. **Роль местоимений в речи.** | 1 | | | |
| 65 | Алмашлык бүлеген кабатлау Рәсем буенча хикәя язу**.** Үз-үзеңне тикшер!<br>**Повторение раздела «Местоимение». Написать рассказ по рисунку.Проверь себя!** | 1 | | | |
| Сан сәг (2 сәгать) | | | | | |
| 66 | Сан мәгънәсе, сораулары, предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме.<br>**Имя числительное, значение, вопросы** | 1 | | | |
| 67 | Сан төркемчәләре, микъдар саннары, тәртип саннары.Санның исем белән куллану үзенчәлеге. Җөмләдәге роле.**Количественные числа, порядковые числа. Особенность использования числа с именем существительным. Роль в предложении.** | 1 | | | |
| Кисәкчә (2сәг.) | | | | | |
| 68 | Кисәкчәләрнең сөйләмдә роле. Кисәкчәләрнең сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы. | 1 | | | |
| 69 | Кисәкчәләрне сөйләмдә куллану һәм дөрес язу. | 1 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Бәйлек (3сәг.) | | | | |
| 70 | Ярдәмче сүз төркемнәренең сөйләмдәге роле. Бәйлекләрнең исемнәр һәм алмашлыклар белән килүе. | 1 | | | |
| 71 | Бәйлекләрне сөйләмдә куллану һәм дөрес язу. | 1 | | | |
| 72 | Кисәкчә, бәйлек бүлеген кабатлау.Үз-үзеңне тикшер! | 1 | | | |
| | Рәвеш (5сәг.) | | | | |
| 73 | Рәвеш турында төшенчә.Рәвеш – мөстәкыйль сүз төркеме, лексик – грамматик яктан эш – хлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә.**Наречие** | 1 | | | |
| 74 | Рәвешләр ярдәмендә эш-хәрәкәтне ачык, аңлаешлы итү. Рәвешнең сораулары: ничек?, кайчан?, кая?, никадәр?,күпме?**Вопросы наречий : когда? куда? где? сколько? сколько?** | 1 | | | |
| 75 | Рәвешләрен сөйләмдә куллану һәм дөрес язу<br>**Правописание наречий, активно используемых в речи.** | 1 | | | |
| 76 | Рәвеш темасын ныгыту . **Повторение темы “Наречие”.** | 1 | | | |
| 77 | Рәвеш бүлеген кабатлау.Үз-үзеңне тикшер! **Повторение раздела “Наречие”.Проверь себя!** | 1 | | | |
| | Җөмлә (15сәг.) | | | | |
| 78 | Җөмләдә иярчен кисәкләрне тану. Иярчен кисәкләр – ия белән хәбәрдән тыш сүзләр.<br>**Второстепенные члены.** | 1 | | | |
| 79 | Аергыч. Аергычның сораулары: нинди?, кайсы?, ничәнче?, кемнең?, нәрсәнең?**Определение.** | 1 | | | |
| 80 | Аергычны ияртеп килгән сүз. Аергыч һәм аерылмыш. Билгеләмә бирү.<br>**Главное и зависимое слово в словосочетаниях** | 1 | | | |
| 81 | Тәмамлык. Тәмамлык – эш – хәрәкәтне белдергән сүзне ачыклый. Сораулар: кемне?, нәрсәне?, кемгә?, нәрсәгә?, кемнән?, нәрсәдән?,кемдә?, нәрсәдә?**Дополнение.** | 1 | | | |
| 82 | Тәмамлык. Ныгыту. **Дополнение. Закрепление.** | 1 | | | |
| 83 | **Сочинение.** | 1 | | | |
| 84 | Хәл. (Җөмлә кисәге) Хәл – эш яки хәлнең урынын, вакытын, сәбәбен, максатын белдерә.<br>**Обстоятельство.** | 1 | | | |
| 85 | Хәл. Җөмләдә хәлләрне билгеләү. Ныгыту. **Обстоятельство. Закрепление.** | 1 | | | |
| 86 | Җөмлә тикшерү. Җөмлә тикшерү ысулы. | 1 | | | |
| 87 | Җөмлә тикшерү. Ныгыту | 1 | | | |
| 88 | Иярчен кисәкләрнең тиңдәшләнеп килүе.**Однородные члены предложения** | 1 | | | |
| 89 | Гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә бирү. Тезмә кушма җөмләләр. Составында 2 – 3 гади җөмлә булган кушма җөмләләр.**Простые и сложные предложения.Сложносочиненные** | 1 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **предложения. Сложные предложения , всоставе которых 2-3 простых предложений.** | | | | |
| 90 | Тезмә кушма җөмләләрдә һәм, да/дә, та/тә, ә, ләкин, әмма, чөнки теркәгечләре. | 1 | | | |
| 91 | Җөмлә бүлеген кабатлау.Үз-үзеңне тикшер!**Повторение раздела ―Предложение‖. Проверь себя!** | 1 | | | |
| 92 | **Изложение.** | 1 | | | |
| Текст (9сәг.) | | | | | |
| 93 | Текст. Текст билгеләре. Текстның эчтәлеге һәм төзелеше. Кызыл юл турында төшенчә.**Текст.Особенности текста. Смысловое единство предложений в тексте. Части текста.** | 1 | | | |
| 94 | Текстта мәгънәви эзлеклелекне булдыруга ярдәм иткән сүзләр.**Последовательность текста.** | 1 | | | |
| 95 | Сөйләм төзелеше. План.**Речевое построение.** | 1 | | | |
| 96 | Текст өлешләрендәге эчтәлек.**Содержание в текстовых частях.** | 1 | | | |
| 97 | **Еллык контроль диктант** | 1 | | | |
| 98 | Текстларны сүрәтләү чаралары кулланып язу. Сүрәтләү, фикерләү текстларын аеру. Сүрәтләү, хикәяләү, фикерләү текстлары, аларның үзенчәлекләре.**Написание текстов с применением изобразительных средств.Текст - описание, текст - повествование, текст - рассуждение, их особенности.** | 1 | | | |
| 99 | Текст бүлеген кабатлау. Үз-үзеңне тикшер!**Повторениераздела‒Текст.Проверьсебя!** | 1 | | | |
| 100 | **Сочинение.Текстларны сурәтләү чаралары кулланып язу.** | 1 | | | |
| 101 | Текст бүлеген кабатлау. Котлау тексты һәм хат язу.Үз-үзеңне тикшер!**Повторениераздела‒Текст‖.Текст-поздравлениеиписьмо.Проверьсебя!** | 1 | | | |
| 102 | Йомгаклау. 4нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау.**Обобщение. Повторение изученного в 4 классе.** | 1 | | | |
| 103 | Сүз төркемнәрен кабатлау. **Повторение частей речи** | 1 | | | |
| 104 | Җөмлә кисәкләрен кабатлау**Повторение членов предложения.** | 1 | | | |
| 105 | Җөмлә тикшерү | 1 | | | |

## Контрольно – измерительные материалы
## по предмету «Родной язык» 1 класс

**<u>Күчереп язу.</u>**

**Бакчада.**

Безнеңбакчабыз бар. УлКазансуегласыянындаурнашкан. Андаалмагач, карлыган, чия агачларыүсә. Мин бакчадачәчәкләрүстерәм.

**Кышкы көн.**

Салкын кыш килде. Бөтенҗирнеак кар каплады. Балаларурамгачыкты. Кулларындакөрәк, чиләк. Алар кар тавыясадылар. Аңа су сиптеләр. Икенчекөннетаудан чана шудылар.

**Аю.**

КаюмбеләнӘюпурманга барды. Малайларҗиләкҗыябашлады. Ерактаалараюкүрделәр. Балаларюкәагачыартындакачыптордылар.Аю урман эченәкерепюгалды.

**<u>Диктант.</u>**

**Паркта.**

Туганягыбызга кыш килде. Балалар паркка килделәр. Җиргәак кар ява. Марат чана шуа. Гүзәлчаңгыалды. Аларшуаргаөйрәнә. Балаларга бик күңелле.

**Тиен.**

Тиенурмандаяши. Улчикләвекярата. Җәенкышкаазыкәзерли. Күпитепчикләвекҗыя. Гөмбәкиптерә. Кыш көнетиенагачкуышындаяши.

**Гаилә.**

Минем гаиләм зур һәм тату.Әни белән әти эшли. Мин укучы. Ринат бакчадайөри. Без бергә ял итәбез.

**<u>Күчереп язу.</u>**

**Безнең песи.**

Безнеңпесиебез бар. АныңисемеМыраубатыр. Аныңүзурыны да бар. Мыраубатырбикматурпеси. Аныңалгытәпиләреактөстә. Ә муеныаклы-каралы. Мыраубатыртычканнарнытотаргабикярата. Без дәаныбикяратабыз.

**Карга.**

Берзаманкаргабиксусады. Улберчүлмәкянынакилде. Су чүлмәктөбендәгенәиде. Карганыңборынысугаҗитмәде.
Менә карга чүлмәккәвакташ сала башлады. Чүлмәктәге су өскәкүтәрелде. Карга чүлмәктән су эчте.

**<u>Контроль диктант.</u>**

**Җәй.**

Матур җәй җитте. Җир өстен яшел үлән каплады. Әнәяшел урман. Тар сукмактанбалаларурманга бара. Андакаен, нарат, имәнагачларыүсә. Аланда ал, кызыл, сарычәчәкләрүсә. Чәчәкләргәчуаркүбәләкләркуныпуйныйлар. Матуритепкошларсайрый.

**Бирем:**

1. 1 вариант: 1 нче җөмләне күчереп язарга, тартык авазлар астына сызарга

   2 вариант: 3 нче җөмләне күчереп язарга, сузык авазлар астына сызарга

2. 1 вариант: матур, чәчәкләр, әнә сүзләрен иҗекләргә бүләргә.

   2 вариант: каен, аланда, үсә сүзләрен иҗекләргә бүләргә.

## Контрольно – измерительные материалы
## по предмету «Родной язык» 2 класс
### Контроль эш (кереш)

*1 бирем.* Сүзләрдән сүзләр төзеп яз.

1 вариант: *җәй, үтеп, ямьле, китте, матур*.

2 вариант: *каникулда, әбиләрендә, җәйге, булдылар, балалар.*

*2 бирем*. Сүзләрдә аваз  һәм хәреф санын билгелә.

1 вариант: *ишек, яка.*

2 вариант: *тарак, Әюп*.

*3 бирем*. Бирелгән сүзләр арасыннан юлдан-юлга күчми торган сүзләрне сайлап яз.

*Хат, шикәр, өстәл, китап, елга, җавап, идән, юкә, сыер, төн.*

*4 бирем*. Сүзләргә басым куй.

1 вариант: *савыт, һичбер, барганнар, ничә.*

2 вариант: *кайда, җавап, өчпочмак, бардыңмы.*

*5 бирем*. Бирелгән темага предметның билгесен белдергән сүзләр уйлап яз.

1 вариант: “Көзге урманда”

2 вариант: “Көзге эшләр”

### Контроль күчереп язу.

Авылны әле йокы баскан. Кояш та чыкмаган. Менә берьюлы тәрәзәдә ут кабына. Ишекләр ачыла. Савымчылар эшкә кузгала.

Кешеләр электән үк сыер, кәҗә, дөя саварга өйрәнмәгән булсалар, хәзер безнең өстәлләрдә май, сыр, эремчек тормас иде. Балалар рәхәтләнеп сөт эчмәсләр иде. Кызлар һәм малайлар туңдырманың ни икәнен дә белмәсләр иде.

**Диктант.**

Кызлар гөлләр үстерә.

Өендә гөл үстермәгән кеше юктыр. Безнең өйдә дә, сыйныфыбызда да гөлләр бар. Минем шулар арасында яраткан гөлем бар. Үрмәләп үскән гөлләрне яратам. Алар өйгә ямь бирә.

Грамматик биремнәр:

*1 бирем.* Бирелгән сүзләрне юлдан-юлга күчерерлек итеп бүлеп яз.

1 вариант: *өендә, яраткан, алар.*

2 вариант: *кеше, арасында, үлән.*

*2 бирем*. Бирелгән сүзләрдә **я, е, ю** хәрефләренең авазларын күрсәт.

1 вариант: *ямь, елан, юкә.*

2 вариант: *өендә, ябалак, юрган.*

*3 бирем*. Янәшә тартыклар кергән сүзләр белән җөмлә төзеп языгыз.

**Контроль күчереп язу.**

Куяннар.

Озынколак урманнан чыкты да югарыга сикерде һәм мәтәлчек атып китте. Аннары сикереп торды да арт аякларына басты. Ул озын колакларын уйнатып бии башлады. Озынколак янына икенче куян да чабып килде. Куяннар янәшә бастылар. Алар икәүләшеп биергә керештеләр.

**Ирекле диктант.**

Бүген көн әйбәт кебек иде. Көндез кояш чыкты. Кар өсләре бик матур булып ялтырап яттылар. Тик менә кичкә таба гына әзрәк җил күтәрелде. Эре кисәкле мамыклар кебек кар ява башлады. Аннан буран күтәрелде. Хүзер инде көчле җил бертуктаусыз кар белән уйный, аны туздыра, өя башлады.

**Контроль күчереп язу.**

Безнең якларда күп кенә кошлар кыш көне дә яши. Алар кышын кешеләр тирәсендә чуалалар. Чүп һәм калдык-постык азык ташлана торган урыннарда ала карга, чәүкә, саескан һәм чыпчыкларны күп очратасың. Иген амбарлары, печән кибәннәре тирәсендә дә кошлар аз булмый. Кеше яши торган һәр җирдә алар өчен азык табыла.

**Иҗади диктант.**

Биккуркак.

Биккуркак беркөнне стенада (нинди?) ... әйбер күргән. Колаклары бик (нинди?) ... . (Нәрсәсе?) ... селкенеп тора. Үзе килбәтсез икән. Куркуыннан куян (кайсы?) ... урыныннан кузгала да алмаган. Ярый әле, Бикбатыр килеп (нишләгән?) ... . Биккуркакка бераз (нәрсә?) ... кергән. "Әй юләр, үз шәүләңнән үзең куркып торасың",- дигән (кем?) ... .

**Ирекле диктант.**

Аюлар кышны кар астындагы өннәрендә үткәрәләр. Кар астында җылыда яшәүче бер аю гына түгел. Урман тавыклары да төнне кар астында үткәрәләр. Алар яз буе, җәй буе ялгыз йөриләр. Кышка таба урман тавыклары зур көтү булып җыела. Алар, каен башына утырып, алка, бөре ашыйлар. Тамак туйдыргач, каен төбендәге карга чумалар.

Кешеләр аларның өсләреннән чаңгы белән йөриләр. Шулай булса да, урман тавыгы уянып чыкмый.

**Контроль күчереп язу.**

Берничә ел инде безнең күлгә үрдәкләрнең төшкәне юк иде. Габделхәй аларны ел да көтә. Бәлки, быел төшәрләр?

Габделхәй бүген уйсулыктагы күлгә ялгызы гына тукталачак. Шушы сөзәклектән күтәрелсә, күл уч төбендәге кебек күренәчәе.

Менә ул килеп тә җитте. Һәм кисәк кенә тукталып калды. Күл өстендә бер оя үрдәк йөзә!

**Диктант.**

Карлар эреде. Тамчылар тамды. Язгы сулар акты. Яңгыр яуды. Тамчылар җирнең битен юды.

Җир кипте. Авыл халкы язгы чәчүгә чыкты. Кырда машина тавышлары гөрләде.

Җирне кояш җылыта. Ашлыклар тишелде. Җылы яңгырлар явып узды. Өлгер тамчылар яшь ашлыкларны су белән туендырды.

**Яшь натуралистлар.**

Яшь натуралистлар  эшкә кереште. Рафикъ бөҗәкләр белән мәшгуль. Вәли рәсем дәфтәрен алып утырды. Яхъя папкасын ачты. Ул үзе җыйган үләннәрне кәгазь өстенә җәеп куя бара. Һәр үлән астына исеме язылган кәгазь ябыштыра. Аннан тагын икенче кәгазь белән каплый. Яхъя, үлән ватылмасын дигән кебек, аны саклык белән генә тота.

**Диктант.**

Кара каргалар.

Беренче булып кара каргалар кайтты. Алар кайткач, шатлыкның чиге булмады. Чөнки кара каргалар яз килүен хәбәр иттеләр. Алар болыннарга, кырларга очалар. Зарарлы бөҗәкләрнең чыккан берен юк итәләр. Булдыклы кошлар кырдан кайтмыйлар. Алар безгә зур файда китерәләр.

**Контроль эш.**

**I вариант**

Май

Ямьле май ае килде. Назлы кояш җирне җылытты. Яшен яшьнәп, күк күкрәп, җылы яңгырлар явып узды. Агачлар ефәк кебек яшел яфракларга төренде. Саф яшеллек арасыннан ап-ак чәчәкләр күренде. Һавага ак чәчәкләрдән хуш ис таралды. Җир өстендәге йомшак келәмгә төрле төстәге чәчәкләр сибелде. (42 сүз)

Искәрмә. Өтерләр искәртелә.

*Биремнәр*

**1.** I вариант.1 нче җөмләдә ия астына – бер, хәбәр астына ике сызык сызыгыз.

II вариант. 2 нче җөмләдә ия астына – бер, хәбәр астына ике сызык сызыгыз.

**2.** Янәшә килүче бертөрле тартыкларның астына бер сызык сызыгыз.Бу сүзләрне юлдан юлга күчерү өчен иҗекләргә бүлеп языгыз.

**II вариант**

Әбием куллары

Мин кайчакта әбиемнең кулларына карап торам. Мондый куллар тагын кемдә бар? Ул куллар кечкенә генә, йомры гына. Ләкин шул кечкенә генә куллар белән минем әбием үз гомерендә нәрсәләр генә эшләмәгән... Яңа көн туган саен, шул кечкенә генә кулларга яңадан-яңа эшләр табыла барган. (42 сүз) (Нәби Дәүлидән)

*Биремнәр*

1. Бирелгән сүзләрне күчереп языгыз, кушымчаларын күрсәтегез: *куллар, гомерләр, әбием, эшләр.*

2. Эш сүзенә тамырдаш сүзләр уйлап языгыз.

**Тест**

1. Ике сузык авазлы сүзне билгелә.
а) яшь;
ә) урындык;
б) яшен.
2. Яңгырау тартыклар гына булган сүзне билгелә.
а) тормыш;
ә) урындык;
б) малай.
3. «ь « билгесе язылган сүзне билгелә.
а) Ак..яр;
ә) төн..як;
б) Сәг..ди.
4. Алты сүзле җөмләне билгелә.
а) Әни мине еш мактый.
ә) Җылы яңгырдан соң салават күпере чыкты.
б) Сары чебиләр минем тирәдә йөгерештеләр.
5. Аваз саны хәреф санынннан күбрәк булган сүзне билгелә.

а) томан;
ә) яка;
б) яшь.
6. Ат кушаматын тап.
а) Йомшаккай;
ә) Чаптар;
б) Акбай.
7. Баш хәрефе булмаган хәрефне билгелә.
а) җ;
ә) ң;
б) ю.
8. [э ] авазының хәрефләрен күрсәткән хәрефләр рәтен билгелә.
а) о, ы;
ә) о, ө;
б) е, э.
9. Кем? соравына җавап булган сүзләр рәтен билгелә.
а) биюче, табиб, шагыйрь;
ә) куян, тиен, төлке;
б) дәреслек, бетергеч, карандаш.
10. Дөрес язылган сүзләр рәтен билгелә.
а) йоко;
ә) йыкы;
б) йокы.

**Контрольно – измерительные материалы**
**по предмету «Родной язык» 3 класс**

1. **Кереш контроль диктант.**

**Максат:** Грамоталы язу күнекмәсен тикшерү.

**Дару үләне.**

Сәхипкамал әби икенче көнне Тәнзиләне елга буена алып төште. Яр буендагы дымлы урыннарны эт тигәнәге үләне каплап алган иде. Чәчәкләргә бөреләнгән генә вакытлары. Аларның очларын нәкъ шундый чакта җыярга кирәк.

Дымлы урыннарда песи үләне дә шактый күп иде. Әмма Сәхипкамал әби аларга кагылмады. Аның орлыклары өлгергәч, тамырларын көз көне казып алалар. Йөрәк авыртканда эчә торган валерьянка тамчыларын шулардан ясыйлар инде.

(Хәкимҗан Халиковтан)

Грамматик биремнәр:

1 нче бирем. Сүзләрне иҗекләргә бүл.

1 нче варинат – 1 нче җөмләдә;

2 нче варинат – 2 нче җөмләдә.

2 нче бирем. Түбәндәге биремнәр буенча тексттан сүзләр күчереп яз.

1 нче варинат – 5 авазлы, 5 хәрефле.

2 нче варинат – 6 авазлы, калын әйтелешле.

3 нче бирем. Сүзгә аваз-хәреф анализы яса.

**2 Контроль диктант “Лексика. Сүз. Сүз төзелеше”**

**Максат:** “Лексика. Сүз. Сүз төзелеше” темасы буенча белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Туган көн.

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе, иртүк торып, бик матур торт пешерде. Өстәлгә тәмле-татлы сый-хөрмәт тезелде.

Өстендәге күлмәге дә бик матур бүген Фәридәнең. Анысын да әнисе тегеп кидерде аңа. Чәчләренә күлмәге төсле үк тасмадан күбәләкләр такты.

Өйләре дә искиткеч матур бүген аларның. Бөтен нәрсә ялт иткән! Бар да чиста, бар да пөхтә, бар да матур, күңелле.

Резеда Вәлиевадан.

Грамматтик биремнәр:

1 нче бирем.

Тексттан күчерелмә мәгънәдәге сүзне табып, астына сыз.

2 нче бирем.

Тексттан синоним сүзләрне күчереп яз.

3 нче бирем.

Сүзтезмә белән белдерелгән лексик берәмлекләрне гади карандаш белән әйләндереп ал.

## 3. Контроль диктант “Сыйфат”

Максат: Сыйфат турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Батыр танкист.

Өлкән сержант Рәхим Җиһаншин моңарчы бу илне картадан гына белә иде. Хәзер ул шушы илдә.

Түгәрәк йөзле, кара күзле, чем-кара кашлы бу таза егет Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә армия сафында иде. Ул ак финнарга каршы сугышта да катнашты.

Салкын карлы – буранлы көннәрдә бозлы кыялар һәм калын урманнар, сазлыклар һәм күлләр аша дошманны куа-куа, һәрвакыт алга бардылар. (54 сүз)

Самат Шакирдан.

Грамматик биремнәр:

1 нче бирем: бирелгән сыйфатларны дүрт дәрәҗәгә куеп яз.

1 нче вариант: кара, салкын.

2нче вариант: түгәрәк, таза

2нче бирем: әйтелгән абзацларда сыйфатларны үзләре ачыклап килгән исемнәр белән парлап яз.

1 нче вариант: 2 нче абзац.

2нче вариант: 3 нче абзац.

1 нче бирем: төрле дәрәҗәгә куеп булмаган сыйфатларны күчереп яз.

**4. Контроль күчереп язу. Алмашлык. Текстны исемләү.**

Максат: Алмашлык турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Аю белән хатын

(Татар халык әкияте).

Әүвәлге заманда бер хатын урак урырга баласы белән барган, ди. Ул ара башлагач ук аның янына бер Аю килгән. Ул аюның аягына шырпы кадалган икән, ди.  Ул хатынга аягын күрсәтергә килгән булган. Хатын аның аягыннан шырпысын алган. Шуның өчен Аю хатынга бер умарта бал китереп биргән, ди.

З.И.Җамалетдинова. Татар теле дәресләре. 3 нче сыйныф

5. **Контроль диктант.** “Алмашлык” темасын кабатлау

Максат: Алмашлык турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Янар тау.

Урал борылышы артыннан өч вулкан – өч янар тау күренә башлады. Алар бик якын тоела. Ләкин ерак икәнен яхшы белә Зуфирәю. Аларның ак түбәләре кичке шәфәкаъ нурында коена. Иң биегенең очыннан күксел томан күтәрелә. Югарыда ул кып-кызыл төскә манылган. Томан түгел, янар тауның кайнар сулышы бу. (46 сүз)

Мәдинә Маликова.

Грамматик биремнәр.

1 нче бирем.

Алмашлыкларны күчереп яз, янәшәсендә кайсы затка караганын билгелә.

2 нче бирем. Алмашлыкларны үзләре алмаштырып  килгән сүзләрне парлап. Яз.

*3 нче бирем.

Җөмләне сорау алмашлыгы кертеп үзгәртеп яз.

6. **Контроль күчерепязу.**

Максат: Хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Матур кошлар.

Чәрелдәвек – матур кош. Ул сыерчык хәтле диярлек. Түше кызгылт – сары, баш түбәсендә артык тырпаеп торган карасу – кызгылт “чәче” үзенә бик килешә. Канатлары кара, сары һәм кызыл төсләр белән бизәлгән.

Карабүреккә юкка гына шундый исем бирмәгәннәр. Ул, чыннан да, башына кара бүрек кигән шикелле тоела. Түше һәм корсак асты кып-кызыл. (47 сүз).

Касыйм Тәхау.

Грамматик биремнәр:
1 нче бирем. Әйтелгән җөмләләрдә хәбәрнең астына сыз, кайсы сүз төркеме белән белдерелгәнен күрсәт.
1 нче вариант – 1 нче җөмләдә.
2 нче вариант – соңгы җөмләдә.
1 нче бирем. Текст эчтәлегенә туры килгән җөмләләр уйлап яз.
1 нче вариант – сорау җөмләләр.
2 нче вариант – боеру җөмләләр.
*3 нче бирем. Җөмләне тойгылы җөмләгә әйләндереп яз.
1 нче вариант – җөмләне;
2 нче вариант – җөмләне.
2 нче бирем. Текст эчтәлеге буенча биремнәр буенча җөмләләр уйлап яз.
1 нче вариант – боеру җөмләләр.
2 нче вариант – сорау җөмләләр.
*3 нче бирем. Тойгылы җөмләләр уйлап яз.

**7. Контроль диктант. Кисәкчә.**

Максат: Кисәкчә турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Шулвакыт ертык болыт иренеп кенә кояшны каплады. Вак кына яңгыр сибәли башлады. Авыл капкасы янында ат пошкырган тавыш ишетелде. Бераздан ул үзе дә күренде. Арбада, иске мылтыгын кочаклап, сунарчы Әләү абый утырган иде. Малайлар, кунак кызын да онытып, аңа таба йөгерделәр. Мин генә каккан казык кебек урынымда басып калдым: Әләү абый янәшәсендә кызгылт төлке сузылып ята иде... (57 сүз)

(Ркаил Зәйдулладан)

Грамматик биремнәр.

1. Кисәкчәләрнең асларына сызыгыз.
2. Бирелгән кисәкчәләр белән җөмлә төзеп языгыз. 1 рәт: ***да, ук, ич***
2 рәт: ***тә, кына, бит.***

**8.Контроль күчереп язу “Җөмлә”**

Максат: Җөмлә турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

**Күңелләрдә мәңге сакланыр.**

Тыныш билгеләрен куеп язарга.

Мәскәү Кремле стенасы буендагы бакчада солдат кабере бар Монда күмелгән батырның исемен берәү дә белми ләкин бу билгесез солдатның үз – үзен аямыйча сугышып үлүен һәркем хәтерли Ул башкалабыз өчен барган сугышларның берсендә һәлак булган

Дошман җиңелде Мәскәүгә үтеп керә алмады

1965 нче елда, Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, Мәскәүгә герой – шәһәр исемен бирделәр Башкалабыз өчен барган соңгы сугышларда һәлак булган батырның гәүдәсен казып алдылар да Кремль стенасы буена күмделәр

Менә хәзер шушы кабер өстендә Мәңгелек ут яна (74 сүз)

**9.Контроль диктант “Җөмләнең баш кисәкләре”**

Максат: Җөмләнең баш кисәкләре турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Яз җитә.

Табигатьтә яз билгеләре күренде. Еракта каралып торган урман да яшәрде. Көн урталарында урман өстендә зәңгәр нур балкый.

Кыш буе ак мамык шикелле, түбәләрдә күпереп яткан карлар тыгызланды, басылды. Түбә читләрендә карандаш очы кадәрле бозлар күренгли башлады. Чана юллары карала төште. Менә кара каргалар да су буендагы биек тал агачларына оя ясадылар.

Кояш та хәзер җиргә турырак карый. Ул әкренләп табигатьне җанландырды.

Гариф Галиев буенча.

Грамматик биремнәр.

1 нче бирем. Әйтелгән җөмләләрдә баш кисәкләрнең асларына сыз.

1 нче вариант – 1,2 нче җөмләдә.

3 нче вариант – 3 нче, соңгы җөмләдә.

2 нче бирем. Тиңдәш хәбәрле җөмләне табыгыз, тиңдәш хәбәрләр астына сызыгыз.

*3 нче бирем. 1 нче абзацтагы җөмләләрне җыйнак җөмләгә әйләндереп яз.

**10.Контроль күчереп язу.**

Максат: Белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен тикшерү.

**Солтания белән күбәләк.**

Көн бик эссе. Солтаниянең бик тә, бик тә тәмле туңдырма ашыйсы килә. Ул әле бик кечкенә, аңа бары дүрт яшь кенә. Кечкенә булса да, урамга берүзе генә чыкты әле менә.

Солтания тирә-якка күз салды, ләкин ул якын-тирәдә туңдырма сатучы күрмәде. Инде кая барырга дип торганда, Солтания һавада бөтерелеп очкан бер матур күбәләкне шәйләп алды. Туңдырма ашыйсы килүен онытып, Солтания әлеге күбәләк артыннан китте. Матур күбәләк аның үз артыннан ияргәнен сизде, ахры, тиз генә юлның теге ягына очты. Солтания янә артыннан иярде...

Нәкыйп Каштанов.

**Уку елының II яртыеллыгына тест**

Максат: 3 нче сыйныфта өйрәнелгән белем-күнекмәләрнегомумиләштереп, гамәлдә куллана белү күнекмәсен тикшерү.

**1.** Өйрәнгән сүз төркемнәрен кулланып, түбәндәге биремнәр буенча җөмлә уйлап языгыз. (2 балл)

1 нче рәт: кошлар турында.

2 нче рәт: дуслык турында.

2. Сүзләргә икешәр төрләндергеч һәм ясагыч кушымча өстәп күчереп языгыз. (2 балл)

1 нче рәт: күз, боз.

2 нче рәт: сүз, кар.

3. Бирем буенча җөмлә уйлап языгыз. ( 1 балл)

1 нче рәт: кушма сүз кергән.

2 нче рәт: парлы сүз кергән.

4. Биремнәр буенча өч җөмләдән торган кечкенә текст төзеп языгыз. (3 балл)

1 нче рәт: *Язгы көн*.

2 нче рәт: *Язгы урман.*

5. Фигыльләрне юклык формасында кулланып, өч җөмлә уйлап языгыз. (3 балл)

З.И.Җамалетдинова. Татар теле дәресләре. 3 нче сыйныф

Бәяләү критерийлары:

8 балл – “5”ле

6-7 балл – “4” ле

4-5 балл – “3” ле

4 тән түбән – “2” ле

**Еллык контроль контроль диктант**

Максат: 3 нче сыйныфта өйрәнелгән белем-күнекмәләрнегомумиләштереп, гамәлдә куллана белү, хатасыз язу күнекмәсен тикшерү.

Июнь ае – табигатьнең иң матур, иң яшь чагы.

Таң ата. Бабам бакчадагы умарталыкка китте. Мин дә аның артыннан иярдем. Бакчадагы һәр җиләк-җимеш төймәсендә чык тамчысы җемелди. Дөнья уянып килә.

Умарталардагы бал кортлары да кузгалды. Алар тирә-яктагы гөлләр дөньясына таралды. Бу эшчән бөҗәкләр чәчәкләр тирәсендә ыгы-зыгы киләләр. Һәрбер умарта корты, тырыша-тырыша, бал җыя. Бергенә корт та эшсез тормый.

Һавада тәмле ис – бал исе аңкый. (64 сүз)

( Гарәфи Хәсәновтан)

**Контроль изложение.**

Максат: Ишетеп кабул иткән текстның эчтәлеген бирә белү һәм хатасыз язу күнекмәсен тикшерү.

Аккош.

Урманда бер күл бар. Күл буенда кечкенә йортта каравылчы бабай яши.

Көннәрнең берсендә бабай күлдәге камыш арасында аккош баласы күрә. Ул аны тотып өенә алып кайта да тәрбияләп үстерә. Бабай иртән торып балыкка китә, ә аккош күлдә йөзә, җим ашый.

Бабайның эте Сурка да аккош белән бик тиз дуслашты. Алар бергәләп йөрергә чыктылар. Аккош суда йөзә, ә Сурка яр буйлап бара.

Көз көне көньякка китүче аккошлар күлгә ял итәргә төштеләр. Аккошлар йөриләр, җим ашыйлар, ерак җиргә китәргә көч җыялар. Бабайның аккошы башта алар арасына кермичә, читтә генә йөзеп йөрде. Берничә көннән ул аларга ияләште һәм шул төркем белән көньякка очып китте.

Садри Җәләлдән

**Татар теленнән бәяләү нормалары**

**Диктантларны бәяләү.**

1. Хатасыз яки 1 тупас булмаган хата ж;ибәрелгән ; дөрес каллиграфия белән матур итеп язылган эшкә “5” ле куела.
2. 3 тән артык хата булмаса һәм ул пөхтә итеп язылса яки хатасыз, ләкин төзәтүләр белән бик үк пөхтә язылмаган эшкә “4” ле куела.
3. 5 орфографик һәм 1 пунктуационхаталыэшкә “3” лекуела.

Укучыларныңязма сөйләм , грамматик һәм орфографиккүнекмәләрен изложение һәм сочинение яздырыптикшерепбула. Буэшләралданәзерлекнигезендә- тиешле аңлатулардан соңгынабашкарыла. Язма сөйләмнеңбу төрләренүзләштерү дәрәҗәсенә караган төп таләпләр: эчтәлекне дөрес һәм эзлеклеитепачыпбирү, хатасызязу

**Изложение һәм сочинениене бәяләү**

1. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә, хаталар булмаса яки 1 хата җибәрелсә (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталарның берсе генә булса), “5”ле билгесе куела.
2. Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса, 3 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталардан бары тик өчесе генә) булса, “4”ле билгесе куела.

3. Текстның төп эчтәлеге нигездә бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса, стиль, логик яктан төгәлсезлекләр булса, 6 хата ((орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталар) җибәрелсә, “3”ле билгесе куела.
4. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса, 7-10 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталар) китсә, “2”ле билгесе куела

Грамматик белемнәрне бәяләү

Ана телендә өйрәнелгән грамматик күренешләрне сөйләмдә дөрес кулланса; тупас булмаган 1-2 хата ж;ибәрсә; укытучыга 1-2 ачыкланучы сорау бирергә туры килсә, “5” ле куела.
Төп таләпләрне үтәп тә, 2 грамматик хата ясаса, ләкин өстәмә сораулар саны 3 тән артмаса, “4” ле куела.
Грамматик форма һәм синтаксис конструкцияләрне сөйләмдә куллана белсә, ләкин 4-5 грамматик хата җибәрсә, “3” ле куела.
Грамматик күнекмәләр начар үзләштерелсә,грамматик кагыйдәләрне сөйләмдә куллана алмаса,хаталар 6 дан артып китсә, ”2”ле куела.

**Тестларны бәяләү**

“5”ле – 95 – 100 % үтәлсә;
“4”ле – 80 – 94 % биремнәргә җавап бирелсә;
“3”ле – 51 – 79 % биремнәр үтәлсә;
“2”ле – 51% тан да кимрәк дөрес җавап булса.

**Күчереп язуны бәяләү критерийлары**

1. Хаталары булмаган, төзәтүләрсез эшкә “5”ле билгесе куела
2. 1-2 хата һәм 1 төзәтелгән хата булса, “4”ле билгесе куела
3. 3 хата һәм 1 төзәтелгән хата булса, “3” ле билгесе куела
4. 4 хата һәм 1 – 2 төзәтелгән хата булса, “2”ле билгесе куела

## Контрольно – измерительные материалы по предмету «Родной язык» 4 класс

### 1. Кереш контроль диктант.

**Максат:** Грамоталы язу күнекмәсен тикшерү.

**Арышлар сөйләшкәндә.**

....Ятам шулай хозурланып, төрле уйларга чумып. Җир әйләнсә шыгырдар иде ул. Арба тәгәрмәче шыгырдый бит. Туктале, болай өскә карап ятканда, җир чыннан да әйләнгән сыман икән ул. Әнә арыш башаклары күчә, болытлар артта кала. Юк, алай түгел, болытлар бара, без бер урында гына торабыз. Аларны җил этеп күчерә. Минем әллә ничә тапкыр күргәнем бар.

.....Кыштыр-кыштыр килеп, нидер көйли, нидер җырлый бугай бу арышлар. Их, аңласаң иде аларның телләрен!

Фоат Садриев

З.И.Җамалетдинова. Татар теле дәресләре. 4 нче сыйныф

Грамматик биремнәр:

1 нче бирем. *Хозурланып, өскә* сүзләренә синоним һәм антонимнар уйлап яз.

2 нче бирем. Тексттан синонимнарны табып яз.

**Изложение.**
**Яхшылык кире кайта.**

Малайны әнисе кибеткә җибәргән иде. Ул ипи, сөт, казылык, катык алды да урам буйлап өйгә атлады. Биш-алты адым ара уздымы, каршында – маэмай! Койрыгын селкеп, борынын суза-суза яхшы атлана.

Малай аңа ипи сындырып бирде, казылык белән сыйлады. Аннары этне яратып сыйпады да юлын дәвам итте.

Өйгә кайткач әнисеннән шелтә эләкте эләгүен. Ләкин малай андый гына әрләүгә түгел, катырагына да түзәргә әзер иде. Һәм ул хаклы иде. Аның хаклы булуы тиз арада расланды.

Беркөнне мәктәптән кайтканда бер көтү эт һау-һаулап аның өстенә ташланды. Малай сумкасын салып селтәнә башлады. Этләр тешләрен ыржайтып өскә сикермәкче була.

Шул вакыт араларыннан берсе алгарак чыкты да эт өеренә каршы ташланды. Эт көтүе чигенергә мәҗбүр булды.

Малай аны яклаган этнең теге вакытта үзе сыйлаган эт икәнен таныды.

**Грамматик биремле диктант.**

Карчык күзлеген борын очына таба шдырып төшерде дә бүлмәне күзлеге өстеннән карарга тотынды. Аннары аны маңгаена таба күтәреп, пыяла астыннан күз йөртеп алды. Бала-чага ише вак-төякне эзләгәндә, аңа күзлек аша бик сирәк карарга туры килә, чөнки ул аны матурлык өчен генә алган иде. Күзлекнең аңа бөтенләй кирәге юк. Ул аны беркайчан да кигәне булмады. Башта ул каушап калгандай булды. Аннан, ачуланмыйча гына, качып утыручы малайга ишетелерлек итеп кычкырып куйды.

<u>Грамматик биремнәр:</u>

1. Тексттан биремнәр буенча сүзләрне табып яз.
   1 в.- парлы сүзләр; 2 в.- сүз ясагыч кушымчалы сүзләр.
2. Тексттан кушма сүзне табып яз. Ул сүзнең беренче тамыры белән тагын өч кушма сүз уйлап яз, тамырларын күрсәт.
3. *Рус теленнән кергән бер алынма кушма сүз белән җөмлә төзеп яз. Кушма сүзне сүз төзелеше ягыннан тикшер.

## 2. Контроль диктант “Лексика. Сүз. Сүз төзелеше”

**Максат:** “Лексика. Сүз. Сүз төзелеше” темасы буенча белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Туган көн.

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе, иртүк торып, бик матур торт пешерде. Өстәлгә тәмле-татлы сый-хөрмәт тезелде.

Өстендәге күлмәге дә бик матур бүген Фәридәнең. Анысын да әнисе тегеп кидерде аңа. Чәчләренә күлмәге төсле үк тасмадан күбәләкләр такты.

Өйләре дә искиткеч матур бүген аларның. Бөтен нәрсә ялт иткән! Бар да чиста, бар да пөхтә, бар да матур, күңелле.

Резеда Вәлиевадан.

Грамматтик биремнәр:
1 нче бирем.
Тексттан күчерелмә мәгънәдәге сүзне табып, астына сыз.
2 нче бирем.
Тексттан синоним сүзләрне күчереп яз.
3 нче бирем.
Сүзтезмә белән белдерелгән лексик берәмлекләрне гади карандаш белән әйләндереп ал.

## 3. Контроль диктант “Сыйфат”

Максат: Сыйфат турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Батыр танкист.

Өлкән сержант Рәхим Җиһаншин моңарчы бу илне картадан гына белә иде. Хәзер ул шушы илдә.

Түгәрәк йөзле, кара күзле, чем-кара кашлы бу таза егет Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә армия сафында иде. Ул ак финнарга каршы сугышта да катнашты.

Салкын карлы – буранлы көннәрдә бозлы кыялар һәм калын урманнар, сазлыклар һәм күлләр аша дошманны куа-куа, һәрвакыт алга бардылар. (54 сүз)

Самат Шакирдан.

Грамматик биремнәр:

1 нче бирем: бирелгән сыйфатларны дүрт дәрәҗәгә куеп яз.

1 нче вариант: кара, салкын.

2нче вариант: түгәрәк, таза

2нче бирем: әйтелгән абзацларда сыйфатларны үзләре ачыклап килгән исемнәр белән  парлап яз.

1 нче вариант: 2 нче абзац.

2нче вариант: 3 нче абзац.

2 нче бирем: төрле дәрәҗәгә куеп булмаган сыйфатларны күчереп яз.

**4. Контроль күчереп язу.  Алмашлык. Текстны исемләү.**

Максат: Алмашлык турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Аю белән хатын

(Татар халык әкияте).

Әүвәлге заманда бер хатын урак урырга баласы белән барган, ди. Ул ара башлагач ук аның янына бер Аю килгән. Ул аюның аягына шырпы кадалган икән, ди.  Ул хатынга аягын күрсәтергә килгән булган. Хатын аның аягыннан шырпысын алган. Шуның өчен Аю хатынга бер умарта бал китереп биргән, ди.

5. **Контроль диктант.** “Алмашлык” темасын кабатлау

Максат: Алмашлык турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Янар тау.

Урал борылышы артыннан өч вулкан – өч янар тау күренә башлады. Алар бик якын тоела. Ләкин ерак икәнен яхшы белә Зуфирәю. Аларның ак түбәләре кичке шәфәкаъ нурында коена. Иң биегенең очыннан күксел томан күтәрелә. Югарыда ул кып-кызыл төскә манылган. Томан түгел, янар тауның кайнар сулышы бу. (46 сүз)

Мәдинә Маликова.

Грамматик биремнәр.

1 нче бирем.

Алмашлыкларны күчереп яз, янәшәсендә кайсы затка караганын билгелә.

3 нче бирем. Алмашлыкларны үзләре алмаштырып килгән сүзләрне парлап. Яз.
*3 нче бирем.

Җөмләне сорау алмашлыгы кертеп үзгәртеп яз.

6. **Контроль күчереп язу.**

Максат: Хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Матур кошлар.

Чәрелдәвек – матур кош. Ул сыерчык хәтле диярлек. Түше кызгылт – сары, баш түбәсендә артык тырпаеп торган карасу – кызгылт “чәче” үзенә бик килешә. Канатлары кара, сары һәм кызыл төсләр белән бизәлгән.

Карабүреккә юкка гына шундый исем бирмәгәннәр. Ул, чыннан да, башына кара бүрек кигән шикелле тоела. Түше һәм корсак асты кып-кызыл. (47 сүз).

Касыйм Тәхау.

Грамматик биремнәр:
1 нче бирем. Әйтелгән җөмләләрдә хәбәрнең астына сыз, кайсы сүз төркеме белән белдерелгәнен күрсәт.

1 нче вариант – 1 нче җөмләдә.
2 нче вариант – соңгы җөмләдә.

4 нче бирем. Текст эчтәлегенә туры килгән җөмләләр уйлап яз.

1 нче вариант – сорау җөмләләр.
2 нче вариант – боеру җөмләләр.

*3 нче бирем. Җөмләне тойгылы җөмләгә әйләндереп яз.

1 нче вариант – җөмләне;
2 нче вариант – җөмләне.
2 нче бирем. Текст эчтәлеге буенча биремнәр буенча җөмләләр уйлап яз.
1 нче вариант – боеру җөмләләр.
2 нче вариант – сорау җөмләләр.

*3 нче бирем. Тойгылы җөмләләр уйлап яз.

## 7. Контроль диктант. Кисәкчә.

Максат: Кисәкчә турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Шулвакыт ертык болыт иренеп кенә кояшны каплады. Вак кына яңгыр сибәли башлады. Авыл капкасы янында ат пошкырган тавыш ишетелде. Бераздан ул үзе дә күренде. Арбада, иске мылтыгын кочаклап, сунарчы Әләү абый утырган иде. Малайлар, кунак кызын да онытып, аңа таба йөгерделәр. Мин генә каккан казык кебек урынымда басып калдым: Әләү абый янәшәсендә кызгылт төлке сузылып ята иде... (57 сүз)

(Ркаил Зәйдулладан)

Грамматик биремнәр.

3. Кисәкчәләрнең асларына сызыгыз.
***4.*** Бирелгән кисәкчәләр белән җөмлә төзеп языгыз. 1 рәт: ***да, ук, ич***
5 рәт: ***тә, кына, бит.***

## 8.Контроль күчереп язу “Җөмлә”

Максат: Җөмлә турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

**Күңелләрдә мәңге сакланыр.**

Тыныш билгеләрен куеп язарга.

Мәскәү Кремле стенасы буендагы бакчада солдат кабере бар Монда күмелгән батырның исемен берәү дә белми ләкин бу билгесез солдатның үз – үзен аямыйча сугышып үлүен һәркем хәтерли Ул башкалабыз өчен барган сугышларның берсендә һәлак булган

Дошман җиңелде Мәскәүгә үтеп керә алмады

1965 нче елда, Җиңү көнен бәйрәм иткәндә, Мәскәүгә герой – шәһәр исемен бирделәр Башкалабыз өчен барган соңгы сугышларда һәлак булган батырның гәүдәсен казып алдылар да Кремль стенасы буена күмделәр. Менә хәзер шушы кабер өстендә Мәңгелек ут яна (74 сүз)

**9.Контроль диктант “Җөмләнең баш кисәкләре”**

Максат: Җөмләнең баш кисәкләре турында белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен үстерү, тикшерү.

Яз җитә.

Табигатьтә яз билгеләре күренде. Еракта каралып торган урман да яшәрде. Көн урталарында урман өстендә зәңгәр нур балкый.

Кыш буе ак мамык шикелле, түбәләрдә күпереп яткан карлар тыгызланды, басылды. Түбә читләрендә карандаш очы кадәрле бозлар күренгли башлады. Чана юллары карала төште. Менә кара каргалар да су буендагы биек тал агачларына оя ясадылар.

Кояш та хәзер җиргә турырак карый. Ул әкренләп табигатьне җанландырды.

Гариф Галиев буенча.

Грамматик биремнәр.

1 нче бирем. Әйтелгән җөмләләрдә баш кисәкләрнең асларына сыз.

1 нче вариант – 1,2 нче җөмләдә.

6 нче вариант – 3 нче, соңгы җөмләдә.

2 нче бирем. Тиңдәш хәбәрле җөмләне табыгыз, тиңдәш хәбәрләр астына сызыгыз.

*3 нче бирем. 1 нче абзацтагы җөмләләрне җыйнак җөмләгә әйләндереп яз.

**10.Контроль күчереп язу.**

Максат: Белемнәрне тикшерү, хатасыз язу ккүнекмәсен тикшерү.

**Солтания белән күбәләк.**

Көн бик эссе. Солтаниянең бик тә, бик тә тәмле туңдырма ашыйсы килә. Ул әле бик кечкенә, аңа бары дүрт яшь кенә. Кечкенә булса да, урамга берүзе генә чыкты әле менә.

Солтания тирә-якка күз салды, ләкин ул якын-тирәдә туңдырма сатучы күрмәде. Инде кая барырга дип торганда, Солтания һавада бөтерелеп очкан бер матур күбәләкне шәйләп алды. Туңдырма ашыйсы килүен онытып, Солтания әлеге күбәләк артыннан китте. Матур күбәләк аның үз артыннан ияргәнен сизде, ахры, тиз генә юлның теге ягына очты. Солтания янә артыннан иярде...

Нәкыйп Каштанов.

**Уку елының II яртыеллыгына тест**

Максат: 4 нче сыйныфта өйрәнелгән белем-күнекмәләрнегомумиләштереп, гамәлдә куллана белү күнекмәсен тикшерү.

1. Өйрәнгән сүз төркемнәрен кулланып, түбәндәге биремнәр буенча җөмлә уйлап языгыз. (2 балл)
   1. нче рәт: кошлар турында.

2.нче рәт: дуслык турында.

2. Сүзләргә икешәр төрләндергеч һәм ясагыч кушымча өстәп күчереп языгыз. (2 балл)
   1 нче рәт: күз, боз.

   2 нче рәт: сүз, кар.

3. Бирем буенча җөмлә уйлап языгыз. ( 1 балл)

   1 нче рәт: кушма сүз кергән.

   2 нче рәт: парлы сүз кергән.

4. Биремнәр буенча өч җөмләдән торган кечкенә текст төзеп языгыз. (3 балл)

   1 нче рәт: *Язгы көн*.

   2 нче рәт: *Язгы урман.*

5. Фигыльләрне юклык формасында кулланып, өч җөмлә уйлап языгыз. (3 балл)

Бәяләү критерийлары:

8 балл – “5”ле

6-7 балл – “4” ле

4-5 балл – “3” ле

4 тән түбән – “2” ле

**Еллык контроль контроль диктант**

Максат: 3 нче сыйныфта өйрәнелгән белем-күнекмәләрнегомумиләштереп, гамәлдә куллана белү, хатасыз язу күнекмәсен тикшерү.

Июнь ае – табигатьнең иң матур, иң яшь чагы.

Таң ата. Бабам бакчадагы умарталыкка китте. Мин дә аның артыннан иярдем. Бакчадагы һәр җиләк-җимеш төймәсендә чык тамчысы җемелди. Дөнья уянып килә.

Умарталардагы бал кортлары да кузгалды. Алар тирә-яктагы гөлләр дөньясына таралды. Бу эшчән бөҗәкләр чәчәкләр тирәсендә ыгы-зыгы киләләр. Һәрбер умарта корты, тырыша-тырыша, бал җыя. Бергенә корт та эшсез тормый.

Һавада тәмле ис – бал исе аңкый. (64 сүз)

( Гарәфи Хәсәновтан)

**Контроль изложение.**

Максат: Ишетеп кабул иткән текстның эчтәлеген бирә белү һәм хатасыз язу күнекмәсен тикшерү.

Аккош.

Урманда бер күл бар. Күл буенда кечкенә йортта каравылчы бабай яши.

Көннәрнең берсендә бабай күлдәге камыш арасында аккош баласы күрә. Ул аны тотып өенә алып кайта да тәрбияләп үстерә. Бабай иртән торып балыкка китә, ә аккош күлдә йөзә, җим ашый.

Бабайның эте Сурка да аккош белән бик тиз дуслашты. Алар бергәләп йөрергә чыктылар. Аккош суда йөзә, ә Сурка яр буйлап бара.

Көз көне көньякка китүче аккошлар күлгә ял итәргә төштеләр. Аккошлар йөриләр, җим ашыйлар, ерак җиргә китәргә көч җыялар. Бабайның аккошы башта алар арасына кермичә, читтә генә йөзеп йөрде. Берничә көннән ул аларга ияләште һәм шул төркем белән көньякка очып китте.

Садри Җәләлдән

**Татар теленнән бәяләү нормалары**

**Диктантларны бәяләү.**

4. Хатасыз яки 1 тупас булмаган хата ж;ибәрелгән ; дөрес каллиграфия белән матур итеп язылган эшкә “5” ле куела.
5. 3 тән артык хата булмаса һәм ул пөхтә итеп язылса яки хатасыз, ләкин төзәтүләр белән бик үк пөхтә язылмаган эшкә “4” ле куела.
6. 5 орфографик һәм 1 пунктуационхаталыэшкә “3” лекуела.

Укучыларныңязма сөйләм , грамматик һәм орфографиккүнекмәләрен изложение һәм сочинение яздырыптикшерепбула. Буэшләралданәзерлекнигезендә- тиешле аңлатулардан соңгынабашкарыла. Язма сөйләмнеңбу төрләренүзлэштерү дәрәжәсенә караган төп таләпләр: эчтәлекне дөрес һәм эзлеклеитепачыпбирү, хатасызязу

**Изложение һәм сочинениене бәяләү**

5. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә, хаталар булмаса яки 1 хата җибәрелсә (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталарның берсе генә булса), “5”ле билгесе куела.
6. Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса, 3 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталардан бары тик өчесе генә) булса, “4”ле билгесе куела.
7. Текстның төп эчтәлеге нигездә бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса, стиль, логик яктан төгәлсезлекләр булса, 6 хата ((орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталар) җибәрелсә, “3”ле билгесе куела.
8. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса, 7-10 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик хаталар) китсә, “2”ле билгесе куела

Грамматик белемнәрне бәяләү

Ана телендә өйрәнелгән грамматик күренешләрне сөйләмдә дөрес кулланса; тупас булмаган 1-2 хата ж;ибәрсә; укытучыга 1-2 ачыкланучы сорау бирергә туры килсә, “5” ле куела.

Төп таләпләрне үтәп тә, 2 грамматик хата ясаса, ләкин өстәмә сораулар саны 3 тән артмаса, “4” ле куела.

Грамматик форма һәм синтаксис конструкцияләрне сөйләмдә куллана белсә, ләкин 4-5 грамматик хата җибәрсә, “3” ле куела.

Грамматик күнекмәләр начар үзләштерелсә,грамматик кагыйдәләрне сөйләмдә куллана алмаса,хаталар 6 дан артып китсә, ”2”ле куела.

**Тестларны бәяләү**

“5”ле – 95 – 100 % үтәлсә;
“4”ле – 80 – 94 % биремнәргә җавап бирелсә;
“3”ле – 51 – 79 % биремнәр үтәлсә;
“2”ле – 51% тан да кимрәк дөрес җавап булса.

**Күчереп язуны бәяләү критерийлары**

7. Хаталары булмаган, төзәтүләрсез эшкә “5”ле билгесе куела
8. 1-2 хата һәм 1 төзәтелгән хата булса, “4”ле билгесе куела
9. 3 хата һәм 1 төзәтелгән хата булса, “3” ле билгесе куела
10. 4 хата һәм 1 – 2 төзәтелгән хата булса, “2”ле билгесе куела